КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 июль г.Казань № 911

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче; 2020 ел, 24 июль, 621 нче; 2020 ел, 26 октябрь, 956 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1229 нчы; 2021 ел, 21 май, 353 нче; 2021 ел, 19 июль, 586 нчы; 2021 ел, 6 ноябрь, 1055 нче; 2022 ел, 27 гыйнвар, 62 нче; 2022 ел, 15 март, 238 нче; 2022 ел, 22 март, 254 нче; 2022 ел, 16 май, 444 нче; 2022 ел,

23 август, 886 нчы; 2022 ел, 12 сентябрь, 985 нче; 2022 ел, 17 декабрь, 1360 нчы; 2023 ел, 6 февраль, 108 нче; 2023 ел, 2 июнь, 679 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасында (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы):

I бүлекнең «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү, эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору»» бүлекчәсендәге егерме дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга республика дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм халыкның яшәү сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында» 2023 ел, 31 март, 385 нче карарында «Яраклы эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенә мөрәҗәгать иткән инвалидлар санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлеше» индикаторы билгеләнде. 2023 елга күрсәткеч зурлыгы – 65 процент, 2024 елга 70 процент билгеләнде.»;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының 2 нче кушымтасындагы «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасының 4.1.5.1 пунктчасындагы 1 графасында «һәм РФ Хөкүмәтенең 376 номерлы карары» сүзләрен өстәргә:

«Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» ярдәмче программасының I бүлегендәге 3 нче таблицасыннан соң ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин